# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«28» октябрь, 2019 ел Түбән Суык-Су № 20

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә.

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 8 ноябренә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү
- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары сатып алу
- Авыл клубы бинасына су үткәрү
- Зират коймасын ясау, монтажлау
- Балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»